ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                         К А Р А Р
от ______________ 07.05.2024 ПР-77                                    №
_______

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2023-2024 елларда җылыту чорын яңарту турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга, «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләр һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең» 5 пунктына, 06.05.2011 № 354 «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарына ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында 2023-2024 елларның җылыту сезонын тәмамлау һәм 2024-2025 елларның көзге-кышкы чорында җылыту сезонына әзерлек турында» 23.04.2024 елдагы ПР-71 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыручы җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә, шулай ук социаль өлкә учреждениеләре җитәкчеләренә:

2.1. Социаль өлкә объектларына, торак фондына һәм Актаныш муниципаль районының башка объектларына җылылык бирүне 06.05.2024 елдан башларга.

2.2. Җылылык энергиясе бирелгәннән соң 5 көн эчендә җылылык белән тәэмин итү системаларының гидравлик режимнарын көйләүне башкарырга.

3. Әлеге карар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче                                                         Р.А. Ильясов